**ГЛАВА РОЖДЕСТВЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422631д.Дятлово,
ул. Юности, д.1
тел (факс): 8 84378 4-74-98

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РОЖДЕСТВЕНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422631 Дятлово авылы,
Яшьлек урамы, 1 нчы йорт,
тел: 8 84378 4-74-98

**2025 елның 07 ноябре** **10 номер**

# КАРАР

## Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлегенең Дятлово торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлеге Уставының 23 статьясы, «Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлегенең Дятлово торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 19 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка билгеләргә.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлегенең Дятлово торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасында укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2026 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Рождествено авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Рождествено**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **С.М. Гуцу**